**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 март № 185

г. Казань

Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең якынча исемлеге (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең якынча исемлеге);

Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль эшләрнең якынча исемлеге (алга таба – муниципаль эшләрнең якынча исемлеге).

2. Җирле үзидарә органнарына 2016 елда муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) исемлекләрен булдырганда һәм раслаганда муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең якынча исемлегенә һәм муниципаль эшләрнең якынча исемлегенә таянырга тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 март, 185 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең якынча исемлеге**

| т/б | Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар категориясе | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең күләм күрсәткеченең үлчәү берәмлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүче учреждение |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Мәдәният өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләр | | | |
| 1.1. | Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фондларын туплауны һәм саклауны тәэмин итүне оештыру | физик һәм юридик затлар | саклау берәмлекләре | үзәкләштерелгән китапханә системалары, китапханәләр |
| 1.2. | Яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм мәдәни-ял тибындагы учреждениеләр хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру | физик һәм юридик затлар | чаралар | үзәкләштерелгән клуб системалары, мәдәни-ял учреждениеләре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Музей хезмәтләре күрсәтүне оештыру һәм музей фондларын саклауны тәэмин итү | физик һәм юридик затлар | саклау берәмлекләре | музей берләшмәләре, музейлар, галереяләр |
| 1.4. | Кино- һәм видеофильмнар күрсәтү | физик һәм юридик затлар | кино- һәм видеосеанслар | муниципаль киновидеоучреждениеләр |
| 1.5. | Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, бүтән тамаша программалары күрсәтү | физик һәм юридик затлар | спектакльләр, тамашалар | театрлар, ансамбльләр, оркестрлар, концерт заллары, цирклар |
| 2. | Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләр | | | |
| 2.1. | Мәгълүмати программалар булдыру | гражданнар | минут/ел, программа/ел | муниципаль учреждениеләр |
| 3. | Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләр | | | |
| 3.1. | Балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирү | 4 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар | укучылар саны | күппрофильле юнәлештәге өстәмә белем бирүне оештыру |
| 3.2. | Сәнгать-эстетика юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү | 4 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар | укучылар саны | сәнгать-эстетика юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмалары |
| 3.3. | Спорт юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү | өстәмә белем оешмасына керүгә сәламәтлеге торышы буенча каршылыклар | укучылар саны | спорт юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү оешмалары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү | булмаган 4 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар | | |
| 3.4. | Гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү | 6 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар | укучылар саны, класс-комплектлар | гомуми белем бирү оешмалары; интернатлары булган гомуми белем бирү оешмалары; мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү оешмалары |
| 3.5. | Муниципаль район территориясендә һәркем алырлык түләүсез мәктәпкәчә белем бирү | 3 яшьтән алып 7 яшькәчә балалар | бала-көн | мәктәпкәчә белем бирү оешмалары; мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү оешмалары |
| 3.6. | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру | тиешле дәрәҗәдәге белем бирү оешмалары булмаган якындагы торак пунктлардан | км/атна | гомуми белем бирү оешмалары |
| 3.7. | Гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү | гомуми белем бирү оешмаларында укучылар | укучылар саны | гомуми белем бирү оешмалары |
| 3.8. | Гомуми белем бирү оешмаларының интернатларында яшәүче тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш һәм | гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм гомуми белем бирү | укучылар саны | интернаты булган гомуми белем бирү оешмалары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | санитария-гигиена хезмәте күрсәтүне, тукклануны, буш вакытын, көнкүрешен һәм ялын оештыруны тәэмин итү | оешмаларының интернатларында яшәүчеләр | | |
| 3.9. | Муниципаль район, шәһәр округы балалары ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру | гомуми белем бирү оешма-ларында укучылар | кеше | гомуми белем бирү оешма-лары |
| 3.10. | Үсешендә, укуында, белем бирү мохитына җайлашуда проблемалары булган балаларга, яшүсмерләргә психологик-медик-педагогик ярдәм күрсәтү | Россия Федерациясе территориясендә яшәүче, гражданлыгына бәйсез рәвештә оешмага алынырга сәламәтлеге торышы ягыннан каршылыклар булмаган, ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән башка белем бирү оешмасы тарафыннан җибәрелгән үзләре, ата-аналары (законлы вәкилләре) башлангычы белән ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән 3 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар | кеше | психолог-педагог һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен белем бирү оешмалары |
| 4. | Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләр | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Өстәмә белем оешмаларының һәм олимпия резервы училищесының уку-тренировка процессын оештыру өчен спорт корылмалары бирү | өстәмә белем оешмалары һәм олимпия резервы училищесы | кв.метр/сәг. | физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт корылмалары |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 март, 185 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль эшләрнең якынча исемлеге**

| т/б № | Муниципаль эш исеме | Муниципаль эштән файдаланучылар категориясе | Муниципаль эшнең күләм күрсәткеченең үлчәү берәмлеге | Муниципаль эшне башкаручы учреждение |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә муниципаль эшләр | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары хокукый актларын, бүтән рәсми мәгълүматны халыкка игълан итү (рәсми бастыру) | халык | эшләр | басма массакүләм мәгълүмат чаралары |
| 2. | Гомуми тармак эшләре | | | |
| 2.1. | Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан идарә карарларын кабул итү процессына методик булышлык күрсәтү | учреждениеләр | эшләр | медицина мәгълүмат-аналитика үзәкләре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2.2. | Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә методик эш | учреждениеләр | эшләр | психологик-медик-социаль булышлык күрсәтү үзәкләре; психологик-педагогик диагностика һәм консультация бирү үзәкләре; диагностика һәм консультация бирү үзәкләре; мәгълүмат-методика үзәкләре; яшьләр сәясәте үзәкләре |
| 2.3. | Муниципаль торак фондын карап тоту эшләрен оештыру | халык | эшләр | торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү учреждениеләре |
| 2.4. | Территорияне төзекләндерүне оештыру | халык | эшләр | торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү учреждениеләре |
| 2.5. | Янгын куркынычсызлыгының беренче чараларын тәэмин итү | юридик һәм физик затлар | эшләр | янгын-коткару отрядлары |
| 2.6. | Капиталь төзелеш объектын төзү буенча заказчы вазыйфаларын башкару | юридик затлар | эшләр | капиталь төзелеш идарәләре |
| 3. | Икътисад өлкәсендә муниципаль эшләр | | | |
| 3.1. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә физик һәм юридик затлардан кирәкле документларны кабул итүне, аларны теркәүне һәм бирүне оештыру һәм гамәлгә ашыру | юридик һәм физик затлар | эшләр | күпфункцияле үзәкләр |
| 4. | Яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль эшләр | | | |
| 4.1. | Балалар һәм яшьләрнең буш вакытын оештыру | 6 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | яшәү урыны буенча яшьләр үзәкләре; яшүсмерләр клублары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4.2. | Яшьләр арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалауда дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, хокук саклау органнарына булышлык күрсәтү | 14 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре |
| 4.3. | Укучыларны, студентларны һәм эшсез яшьләрне вакытлы, сезонлы һәм даими эшләргә урнаштыруда булышлык күрсәтү | 14 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | студентларның хезмәт отрядлары үзәкләре; яшьләр үзәкләре |
| 4.4. | Тормышта авыр хәлдә калган балаларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) һәм яшьләргә телефон аша ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү | 18 яшькәчә гражданнар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), 18 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | балаларга һәм яшьләр психологик-педагогик ярдәм үзәкләре; «Яшьләр ышагы телефоны» ашыгыч психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе; яшьләр үзәге |
| 4.5. | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыруны тәэмин итү | 4 яшьтән алып 18 яшькәчә гражданнар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), 18 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | «Ял» балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, аларның ялын, эш белән тәэмин ителешен оештыру буенча шәһәр үзәге» Казан шәһәре яшьләр сәясәтенең муниципаль бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4.6. | Тереклек эшчәнлеген социаль-көнкүреш ягыннан тәэмин итү, психологик-педагогик ярдәм һәм социаль-хокукый яклау мәсьәләләре буенча консультатив ярдәм | гражданнар | эшләр | балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләре |
| 4.7. | Яшьләр арасында социаль яктан тискәре күренешләрне профилактикалау, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар үткәрү | 14 яшьтән алып 30 яшькәчә гражданнар | эшләр | балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләре, яшьләр үзәкләре |